| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

Матак авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2018 ел №10

Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.09.2010 ел, № 681 карары (01.10.2013 ел, № 860 карар редакциясендә) белән расланган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге территориясендә эшләнгән терекөмешле лампаларны җыю һәм туплау, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.09.2010 ел, № 681 карары (01.10.2013 ел, № 860 карар редакциясендә) белән расланган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә башкарырга.

2. Матак авыл җирлеге территориясендә кушымта нигезендә кулланылган терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарын билгеләргә ((милекче, яллаучы, күпфатирлы йортлардагы биналардан файдаланучы һәм әлеге биналарның милекчеләре төзегән күпфатирлы йортлар белән идарә итү

шартнамәсе яки хезмәт күрсәтү һәм (яки) карап тоту буенча эшләр башкару килешүе булган терекөмешле лампаларны кулланучылардан тыш)э.

3. Халыкка аңлатырга: Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.09.2010 ел, № 681 карары (01.10.2013 ел, № 860 карар редакциясендә) белән расланган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 10.1 пункты нигезендә, җыю һәм урнаштыру урынына кадәр мөстәкыйль транспортта, шундый ук зурлыктагы лампаларның сакланышын тәэмин итә торган тарада рөхсәт ителә.

4. Матак авыл җирлеге башлыгының « Матак авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны җыю һәм туплауны оештыру тәртибен раслау турында»08.11.2012 ел, №11 карарын гамәлдән чыгарырга.

5. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан республикасы Чүпрәле районы
Матак авыл җирлеге башлыгы: В.М.Михайлов